ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2023 с.Старое Дрожжаное № 270

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Шәйморза урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең - «Кече Шәйморза башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең филиалын бетерү турында

Бюджет акчаларын тотуны оптимальләштерү максатларында, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законның 9, 22 ст. нигезендә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-64 статьяларына, “Коммерциягә карамаган оешмалар турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законның 18 статьясына, Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып, Иске Шәйморза авыл җирлегендә яшәүчеләрнең җыелышы беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Шәйморза урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең - «Кече Шәйморза башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең филиалын бетерергә.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Шәйморза урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Кече Шәйморза башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалын юкка чыгару срогын - әлеге карарга кул куйган көннән алып өч ай дип билгеләргә.
3. МКУ «Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»н ликвидация процедураларын гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Шәйморза урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорына:

4.1. Филиалны бетерү турында Карар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә милекне инвентаризацияләргә кирәк.

4.2. Эксплуатацияләүгә яраксыз һәм тулысынча тузган милекне юкка чыгару буенча чаралар күрергә.

4.3. Уставка, структурага һәм белем бирү учреждениеләренең штат расписаниесенә үзгәрешләр кертергә һәм вәкаләтле органнарда теркәргә.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Шәйморза башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү буенча комиссия төзергә һәм аның составын кушымта нигезендә расларга.

6. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Кече Шәйморза башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең ликвидация комиссиясе җитәкчесенә түбәндәгеләрне йөкләргә:

- Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәтенең 8 нче номерлы районара инспекциясенә муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү турында әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә;

- Татарстан Республикасы буенча «Вестник государственной регистрации» журналының региональ вәкиллегендә муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү турында белдерүне (хәбәрнамәне) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә;

- муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе мөлкәтен инвентаризацияләү үткәрергә һәм аны вәкаләтле органга тапшыруны тәэмин итәргә;

- 2023 елның 1 сентябреннән муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләрен хезмәт законнары нигезендә азат итү чараларын гамәлгә ашырырга;

- муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен закон белән билгеләнгән тәртиптә юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру буенча чаралар күрергә.

7. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 июлендәге 348 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023 елның "27" июнендә
270 номерлы карары белән расланган

Ликвидация комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Ахметов С.Л. | «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе методисты, комиссия рәисе, җаваплы ликвидатор |
| Зялалова Р. М. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе |
| Ханбиков Б.З. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Сафиуллов И.Ф. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Шәйморза урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры |

Башкарма комитет
эшләр идарәчесе Д.Р. Сабирзянова